ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 9 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 86 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 45 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәп, үзгәреш кертергә:

«3. Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан раслана торган тиешле финанс елына һәм план чорына гражданнарга түләүсез медицина ярдәме күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы нигезендә Татарстан Республикасы Россия Федерациясе субъектына Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнарга Россия Федерациясенең тиешле субъекты территориясендә фактта күрсәтелгән мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән авырулар вакытында медицина ярдәме һәм паллиатив медицина ярдәме күрсәтүгә бәйле чыгымнарны Татарстан Республикасы белән Россия Федерациясенең тиешле субъекты арасында төзелә торган, чыгымнарны каплау мәсьәләсен ике яклы җайга салуны үз эченә алган регионара килешүгә таянып каплый. Мондый килешүне төзү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе                                                                                    Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 17 октябрь
№ 83-ТРЗ